**Министерство Образования и Науки Республики Татарстан**

**Исполнительный комитет Сармановского муниципального района**

**МБОУ "Кавзияковская ООШ "**

УТВЕРЖДЕНО

Директор школы

________________________

Фатихов Ш.М.
Приказ №35
от «22» 08.2023 г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**учебного предмета «Родной язык» (Татарский)**

для обучающихся 8 класса

**село Кавзияково 2023**

## Пояснительная записка

Рабочая программа по родному (татарскому) языку для 8 класса составлена на основе федерального государственного образовательного стандарта основного общего образования, на базе примерной программы основного общего образования и учебного плана МБОУ «Кавзияковская ООШ» на 2023-2024учебный год, утверждённого приказом № 35от 22.08.2023 г. Программа рассчитана на 3 часа в неделю. Всего 102часов. Уровень обучения базовый.

**Примечание:** На основании положения муниципального бюджетного образовательного учреждения «Кавзияковская основная общеобразовательная школа» «О структуре, порядке разработки и утверждения рабочих программ, учебных курсов и предметов муниципального бюджетного образовательного учреждения « Кавзияковская основная общеобразовательная школа» Сармановского муниципального района РТ», рассмотренного на педагогическом совете от 23.08.2016 г., протокол № 1, утвержденного положения. Приказом директора № 64 от 23.08.16 г., в случае совпадения уроков с праздничными и каникулярными днями, программу выполнить согласно п. 5.2 данного положения

**Учебное пособие**: "татарский язык: 8 класс: учебное пособие для общеобразовательных организаций на татарском языке. Учебник для 8 класса татарской средней общеобразовательной школы /М. З. Закиев, Н.В. Максимов.- Казань: Татарское книжное издательство, 2015.

**Цель:** реализация требований Федерального государственного стандарта, создание у учащихся лингвистических (языковых), коммуникативных (коммуникативных), культурологических (культурных) компетенций в области национальной культуры. Развитие самосознания, воспитание нации, любви к Родине, чувства гордости и гражданственности.

**Задачи:**

- систематизация знаний учащихся по фонетической, орфоэпической, орфографической, лексической, грамматической основам татарского языка, продолжение обучения в более сложных формах;

- развитие возможностей творческого и самостоятельного мышления учащихся, умение аргументировать свое мнение;

-участвовать в теледебатах и грамматических мероприятиях;

- обучение татарскому литературному языку нормам и стилистическим возможностям, умению их использовать;

- языкознание-приобщение к культуре, языкознанию и культурному единству; изучение языка и культуры; воспитание уважения к духовному наследию татарского и других народов.

**Аңлатма язуы**

**8 нче класс өчен ээ рrограммасы түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп төзелде:**

1. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).

2..«Россия Федерациясенең мәгариф турындагы» федераль законы №273-ФЗ, 29.12.2012

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы МБББУ "Кәүҗияк төп гомуми белем мәктәбе"нең 2023 – 2024 нче уку елына педагогик совет утырышында каралган һәм 22.08.2023 нче елгы № 35 нче карары белән расланган укыту планы (беркетмә №1, 24.08.2022)

**Уку фәненең уку планында тотканурыны**

ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планы буенча татар телен укыту фәненең мәҗбүри өлешендә (база дәрәҗәсе) өйрәнелә.Сарман муниципаль районы МБББУ "Кәүҗияк төп гомуми белем мәктәбе"нең 2022 – 2023 нче уку елына 1-9 нчы класслар өчен төзелгән укыту планында 8 нче сыйныфка туган телдән атнага 2 сәгать каралган. Барысы 70 сәгать. Эш программасында уку елы дәвамында татар теленнән 70 дәрес үткәрү планлаштырыла.

**Искәрмә:** МБББУ «Кәүҗияк төп гомумбелем бирү мәктәбе»нең педагогик киңәшмәсендә каралган һәм директор приказы № 51, п.5.2 23.08.2016 белән расланган «О структуре, порядке разработки и утверждения рабочих программ, учебных курсов и предметов МБОУ «Кавзияковская ООШ» Сармановского муниципального района РТ» дигән положениесе нигезендә бәйрәм көннәргә һәм каникулларга туры килгән дәрес материалларын кабатлау өчен бирелгән сәгатьләрне, охшаш темаларны берләштерү хисабына укытыла.

**Уку әсбабы: "**Татар теле: 8 нче сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбе 8 нче сыйныфы өчен дәреслек /М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015.

**Максат:** Федераль дәүләт стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә, укучыларда лингвистик (тел), коммуникатив (аралашу), милли мәдәният өлкәсенә караган культурологик (мәдәни) компетенцияләр булдыру. Укучының үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү.

**Бурычлар:**

-укучыларның татар теленең фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү;

-укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;

-телнеңтөп грамматик чараларынсөйләмпроцессындакулланугаирешү;

- татар әдәби тел нормаларынһәм стилистик мөмкинлекләренaчыккүзаллауга, аларны тиешенчә куллана белүгә өйрәтү;

-телнеңмилли –мәдәниятнеңчагылышыбулуын, тел һәмтарихбердәмлегенаңлату; татар теленеңмилли-мәдәни үзенчәлегенә төшендерү;

татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү.

**Создание и совершенствование универсальных учебных действий учащихся (УУД) приводит к дальнейшим результатам**.

**Личностные результаты**:

- осознание роли татарского языка в нравственном, духовном и творческом становлении личности как основной национально-культурной ценности татарского народа.;

- воспитывать любовь к родному языку и чувство гордости за него, пробуждать желание и стремление работать в области сохранения и развития родного языка;

- знание состава словаря и грамматических, стилистических средств, необходимых для общения на родном языке, четкого, разностороннего выражения своих мыслей и чувств;

- умение использовать и связывать разговорную речь, связанную с типом и ситуацией общения;

- внимание к речи товарищей, наблюдение за своей речью, исправление ошибок, участие в дискуссии, обсуждение темы с использованием различных аргументов.

**Метапредметные результаты**:

- овладение всеми видами речи (слушание, понимание, чтение, письмо): понимание темы, основного и дополнительного мнения информации, относящейся к письменному и речевому языкам; умение правильно читать и понимать тексты, относящиеся к разным стилям и жанрам; умение собирать информацию из различных источников; умение правильно пользоваться словарями и электронными средствами; умение собирать, анализировать, обрабатывать и изменять материал, относящийся к отдельной теме.;

- основные функции татарского языка, его место среди других тюркских языков, культура, понимание тесной связи языка с обществом;

- создание основы научных знаний о родном языке, понимание взаимосвязи и отношения языковых слоев, ярусов;

- освоение основных понятий языкознания, формирование информации о его отраслях; язык и речь, виды речи, ситуации общения; язык речи, функциональные стили, язык художественной литературы; текст и его виды; основные единицы языка, их отличительные признаки, особенности использования в речи;

- знание основных стилистических мероприятий языка, литературных норм языка, норм речевой литературы, их правильность в речи

научиться использовать;

- умение различать и анализировать языковые и речевые единицы; различать и сравнивать виды речи в зависимости от применения языковых и стилистических средств;

- различать художественные средства языка, знать их эстетические функции.

**Предметные результаты:**

- понимать, что татарский язык-это средство изучения и обучения другим предметам;

- выявление влияния языковых мероприятий на произведения художественной литературы, связав татарский язык с литературой; раскрытие специфики Языково-изобразительных мероприятий, присущих литературе того времени;

- учить язык логически писать, говорить содержание, план, конспект, резюме произведения, связанного с литературой, прочитанного или прослушанного;

- приобщение языка к культуре, уважение к богатству и красоте татарского языка, воспитание вкуса;

## Укучыларның универсаль уку гамәлләрен (УУД) булдыру һәм камилләштерү алдагы нәтиҗәләргә китерә.

**Шәхси нәтиҗәләр**:

- татар теленең татар халкы өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуын, ана телендә шәхеснең әхлакый, рухи һәм иҗади яктан формалашудагы ролен аңлау;
- туган телгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре тәрбияләү, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк, омтылыш уяту;
- туган телдә аралашу, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык, күпьяклы итеп белдерү өчен кирәкле булган сүзлек составын һәм грамматик, стилистик чараларны белү;
- аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм үзара бәйли белү;
- иптәшләренең сөйләменә игътибар итү, үзеңнең сөйләмеңә күзәтеп бәя бирү, хаталарны төзәтү, бәхәстә катнашу, төрле дәлилләр кулланып, тема буенча фикер алышу.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

- сөйләмиятнең барлык төрләрен (тыңлау, аңлау, уку, язу) үзләштерү: язма һәм сөйләм теленә караган мәгълүматның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес уку һәм аңлау; төрле чыганаклардан мәгълүмат туплый белү; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалана белү; аерым бер темага караган материалны туплый, анализлый, эшкәртә һәм үзгәртә белү;
- татар теленең төп функцияләрен, татар теленең башка төрки телләр арасында тоткан урынын, телнең мәдәният, җәмгыять белән тыгыз бәйләнешен аңлау;
- туган тел турындагы фәнни белемнәрнең нигезен булдыру, тел катламнарының, ярусларының үзара бәйләнешен һәм мөнәсәбәтен аңлау;
- тел белеменең төп төшенчәләрен үзләштерү, аның тармаклары турында мәгълүмат булдыру; тел һәм сөйләм, сөйләм төрләре, аралашу ситуацияләре; сөйләм теле, функциональ стильләр, матур әдәбият теле; текст һәм аның төрләре; телнең төп берәмлекләре, аларның аермалы билгеләрен, сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен белү;
- телнең төп стилистик чараларын, телнең әдәби нормаларын, сөйләм әдәбе нормаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү;
- тел һәм сөйләм берәмлекләрен аера һәм анализлый белү; тел һәм стилистик чараларның кулланылышына бәйле рәвештә сөйләм төрләрен аера һәм чагыштыра белү;
    - телнең сәнгати чараларын аеру, аларның эстетик функцияләрен белү.

**Предметара нәтиҗәләре**:

- татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;

- татар телен әдәбият белән бәйләп, тел чараларының матур әдәбият әсәрләрендәге тәэсир көчен, сәнгатьлелеген булдыруда ролен ачыклау; чор әдәбиятына хас тел-сурәтләү чараларының үзенчәлекләрен ачу;
- телне әдәбият белән бәйләп, укыган яки тыңлаган әсәрнең эчтәлеген, планын, конспектын, резюмесын логик эзлекле итеп язарга, сөйләргә өйрәтү;
- телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык тәрбияләү;

**Основное содержание программы**

**Язык и языкознание**. Напомнить разделы языкознания (1ч.)

**Повторение раздела** фонетика, морфология.(3ч)

**Диалог и монолог, прямая и косвеннаяречь**.  Умение выражать понятия диалога, реплики, прямой речи, косвеной речи, цитаты.(6 ч)

**Общее понятие о сложном предложении**. Сложносочиненые предложение. Союзное сложносочиненое предложение с фиксатором и безсоюзноесложносочиненое предложение  и  их связующие средства, знаки препинания.

Умение различать сложносочиненных  предложения, синтаксический анализ (5 ч)

**Сложноподчиненные  предложение**. Синтетическое, аналитическое предложение, связывающие средства, знаки препинания. Синонимичность сложноподчиненных  предложений . Сложноподчиненые предложение и его смысловые виды. Умение различать сложноподчиненых  предложений, синтаксический анализ (22 часа)

**Умение различать сложноподчиненных  предложений, синтаксический анализ** (3 часа)

**Сложные конструкции**. Сложное с предложение. Сложное многослойное предложение. Сложное совместное предложение. Умение составлять схемы (9 часов)

**Повторение сложных конструкций, синтаксический анализ**. Умение различать сложные конструкции, синтаксический анализ. (2 часа).Уметь распознавать колесо, делать синтаксический анализ. (1 час)

**Смысл и строение предложения, интонация и знаки препинания**. Значение и строение предложения, интонация и постановка звуковых знаков (1 час)

**Деловые бумаги и их образцы**. Составление протокола (1 час)

**Письменные работы**. Диктанты. Работа над ошибоками (16 часов)

**Всего 70 ч.**

## Программаның төп эчтәлеге

**Тел һәм тел гыйлеме.** Тел гыйлеменең бүлекләрен искә төшерү (1сәгать)

**Үткәннәрне искә төшерү. Кабатлау.** Фонетика, морфология бүлеген кабатлау.(3сәгать)

**Диалог һәм монолог, туры һәм кыек сөйләм. Туры сөйләм, кыек сөйләм.**Диалог, реплика, туры сөйләм, кыек сөйләм, цитататөшенчәләрен аңлата белү.(6сәгать)

**Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре.**

Тезмә кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау (5сәгать)

**Иярченле кушма җөмлә. Төзелеше буенча синтетик, аналитик иярчен җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре. Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы. Иярчен җөмлә һәм аның мәгънә ягыннан төрләре**

Иярченле кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау (22 сәгать)

**Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау.** Иярченле кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау (3 сәгать)

**Катлаулы төзелмәләр. Катлаулы кушма җөмлә. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә. Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. Тиңдәш ияргүле күп иярченле катлаулы**Катлаулы төзелмәләрне аңлата, схемаларын ясый белү (9 сәгать)

**Катлаулы төзелмәләрне кабатлау, синтаксик анализ ясау.** Катлаулы төзелмәләрне аера белү, синтаксик анализ ясау. (2 сәгать)

**Тезем.**Теземне таный белү, синтаксик анализ ясау. (1 сәгать)

**Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре.** Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләренең куелышы (1 сәгать)

**Эш кәгазьләре.Беркетмә язу.** Эш кәгазьләреннән беркетмә яза белү (1 сәгать)

**Язма эшләр. Диктантлар. Хаталарны анализлау төзәтү эшләре (**16 сәгать)

**Тәрбиянең эш программасын исәпкә алып,. һәр теманы өйрәнү өчен бирелгән сәгатьләр санын күрсәтеп, тематик планлаштыру. 8 сыйныф.**

| № | Бүлекләр темасы | | “Мәктәп дәресе” программасы нигезендә тәрбия модуле |
|---|---|---|---|
| 1 | **Тел һәм тел гыйлеме.** | 1 | Белем бәйрәме көне уңаеннан дәрестә фикер алышу, баланың танып-белү эшчәнлеген активлаштыру; туган телгә хөрмәт тәрбияләү |
| 2 | **Үткәннәрне искә төшерү. Кабатлау.** | 3 | Халыкара грамоталылыкны тарату көне. Укучыларның дәрестә үз-үзләрен тотышының гомумкабул ителгән нормаларын үтәү, |
| 3 | **Диалог һәм монолог, туры һәм кыек сөйләм. Туры сөйләм, кыек сөйләм.** | 6 | Экологик тәрбия. Сәламәтлек һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау дә-ресләре.<br><br>Милли тәрбия.. Татар халкының гореф-гадәтләрен барлау<br><br>Патриотик тәрбия. 1941-45 нче елларда совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүе.Хәтер дәресе |
| 4 | **Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре.** | 5 | Әхлак тәрбиясе. Укучыларда намуслылык сыйфатларын формалаштыру<br>Хезмәт тәрбиясе. Һәр һөнәр дә файдалы<br><br>Акыл тәрбиясе. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **5** | **Иярченле кушма җөмлә. Төзелеше буенча синтетик, аналитик иярчен җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре. Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы. Иярчен җөмлә һәм аның мәгънә ягыннан төрләре** | **22** | Милли тәрбия. Бөтендөнья сәламләү көне. Аралашу дәресе.<br>Патриотик тәрбия. Халыкның милли үзенчәлегендә Ватанга мәхәббәт тәрбияләү<br>Экологик тәрбия. Туган як табигатен саклау |
| 6 | **Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау.** | **3** | Әхлакый тәрбия. Интернет челтәрендә мәктәп укучыларының бөтенроссия куркынычсызлык дәресе. Фән олимпиадалары |
| **7** | **Катлаулы төзелмәләр. Катлаулы кушма җөмлә. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә. Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. Тезем.** | **12** | Милли тәрбия. Бөтендөнья сәламләү көне. Аралашу дәресе.<br>Патриотик тәрбия. Халыкның милли үзенчәлегендә Ватанга мәхәббәт тәрбияләү<br>Экологик тәрбия. Туган як табигатен саклау |
| **8** | **Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре** | **1** | Ватан Геройлары Көне. Батырлык Дәресе |
| **9** | **Бәйләнешле сөйләм үстерү** | **17** | Әхлак тәрбиясе.Кул хезмәте көне. Дәрес-инша. - Проект эшчәнлеге дәресе<br><br>Милли тәрбия. Татар халкының милли бәйрәмнәре.<br><br>Патриотик тәрбия. Үлгәннәрнең каберен, исәннәрнең кадерен бел. |
| | **Барлыгы** | **70** | |

## Календарь-тематик планлаштыру

| | Дәреснең темасы һәм бүлекләре | Дәрес саны | Уку-укыту эшчәнлеге төрләре | Үтәлеш | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | план | факт |
| 1 | **Тел һәм тел гыйлеме**. Кереш. | 1 | Тел гыйлеменең бүлекләрен искә төшерү. Аларның нәрсә өйрәнүләрен кабатлау. | 5.09 | |
| 2 | Үткәннәрне искә төшерү. | 1 | Фонетика, морфология бүлеген кабатлау | 6.09 | |
| 3 | Үткәннәрне кабатлау. | 1 | Гади җөмлә синтаксисын кабатлау | 7.09 | |
| 4 | Диктант№1 | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 13.09 | |
| 5 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. Диалог һәм монолог | 1 | Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе **диалог** дип аталу. Аерым кешеләрнең диалог эчендәге сүзләренең **реплика** дип йөртелүе. | 14.09 | |
| 6-8 | **Туры һәм кыек сөйләм** турында гомуми мәгълүмат. | 3 | Сөйләмнең ике төрле: телдән һәм язма рәвештә булуы. Сөйләмне башкаручының сөйләүче яки автор дип аталуы. Үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләмнең **туры сөйләм** дип, ә үзгәртелеп кулланылган чит сөйләмнең **кыек сөйләм** дип аталуы. Язма әсәрләрдән алынган туры сөйләмнең **цитата** дип аталуы. | 15.09<br>20.09 | |
| 9-10 | Туры сөйләм янында тыныш билгеләре. | 2 | Туры сөйләмнең куштырнаклар эченә алынуы. Туры сөйләм янында тыныш билгеләре куюның өч төргә бүленүе. | 21.09<br>26.09 | |
| 11 | Диалогта тыныш билгеләре | 1 | Диалогта һәр репликаның кызыл юлдан һәм сызык куеп язылуы | 27.09 | |
| 12-14 | Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү. | 3 | Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү үзенчәлекләре белән таныштыру | 28.09<br>3.10<br>4.10 | |
| 15-16 | Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ | 2 | Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ ясый белү | 5.10<br>10.10 | |
| 17 | БСҮ. Иҗади изложение №1 | 1 | Иҗади фикер йөртү сәләтен үстерү максатында | 11.10 | |
| 18 | Изложениене сыйныфта тикшерү, хаталарны төзәтү | 1 | Хаталарны анализлау, бергәләп тикшерү максатында | 12.10 | |
| 19 | **Кушма җөмлә** турында гомуми төшенчә. | 1 | Ике гади җөмләдән торган җөмләнең **кушма җөмлә** дип аталуы. | **17.10** | |
| 20 | Тезмә кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. | 1 | Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмләнең **тезмә кушма җөмлә** дип аталуына төшендерү, теркәгечле тезмә кушма җөмлә , теркәгечсез тезмә кушма җөмлә төрләрен | 18.10 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | аңлату. | | |
| 21-23 | Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. | 3 | Кушма җөмләдәге гади җөмләләрне үзара бәйли торган тезүче теркәгечләр: җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечләр булуы. | 19.10<br>24.10<br>25.10 | |
| 24-26 | Теркәгечле тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | 3 | Теркәгечле тезмә кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләрнең бер-берсеннән өтер белән аерылуы. | 26.10<br>7.11<br>8.11 | |
| 27-29 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | 3 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә, гади җөмләләрне аеру өчен, өч төрле билге куллану: **өтер**, **нокталы өтер**, **сызык.** | 9.11<br>14.11<br>15.11 | |
| 30 | Диктант№2 | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү | 16.11 | |
| 31 | **Иярченле кушма җөмлә турында гомуми төшенчә.** | 1 | Үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмләнең **иярченле кушма җөмлә** дип, ияреп килгәне − иярчен җөмлә, ә ияртеп килгәне баш җөмлә дип аталуы. | 21.11 | |
| 32-35 | Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре. | 4 | Баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән, шунлыктан аңа керешеп киткән җөмләнең синтетик иярчен җөмлә дип аталуы. Синтетик иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасына бер генә билге − бары тик өтер генә куелу. | 22.11<br>23.11<br>28.11<br>29.11 | |
| 36-37 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение | 2 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, камилләштерү. Бердәм республика тестлаштыруына әзерлек | 30.11<br>5.12 | |
| 38-39 | Аналитик иярчен җөмләләр. | 2 | Баш җөмләгә үзенең составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмләләрнең **аналитик иярчен җөмлә** дип аталуы. Аналитик иярчен җөмләләрнең баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр, күтәрү интонациясе белән бәйләнүе. | 6.12<br>7.12 | |
| 40-42 | Аналитик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре. | 3 | Баш җөмләгә парлы мөнәсәбәтле сүзләр һәм ияртүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән иярчен җөмләләр янында өтер куелу. Баш җөмләгә күтәрү паузасы белән бәйләнгән иярчен җөмлә алдыннан һәрвакыт ике нокта куелу. | 12.12<br>13.12<br>14.12 | |
| 43 | Контроль диктант№3 | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 19.12 | |
| 44-46 | Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне кабатлау. | 3 | Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне аера белү. | 20.12<br>21.12<br>26.12 | |
| 47-48 | Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы. | 2 | Синонимик иярченле кушма җөмләләрдә мәгънә, нигездә бер үк булуы, иярчен җөмләләрнең дә бер үк мәгънәле сорауга җавап бирүләре. | 27.12<br>28.12 | |
| 49 | БСҮ. Контроль изложение№2 | 1 | Катлаулы план нигезендә эчтәлекне төгәл итеп бирү. | 9.01 | |
| 50-51 | Иярчен ия җөмләләр. | 2 | Иярчен ия җөмләнең баш җөмләнең иясе урынына килүе һәм кем? нәрсә? сорауларына җавап бирүе | 10.01<br>11.0 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 52-53<br>54-55 | Иярчен хәбәр җөмләләр.<br>Иярчен ия җөмләләр. | 2<br>2 | Иярчен хәбәр җөмләнең баш җөмләнең хәбәре урынында килүе һәм нинди? Нәрсә? Нәрсәдән? Кемгә? Күпме? сорауларына җавап булуы.<br>Иярчен ия җөмләнең баш җөмләнең иясе урынына килүе һәм кем? нәрсә? сорауларына җавап бирүе | 16.01<br>17.01<br>18.01<br>23.01 | 11 |
| 56-57 | Иярчен тәмамлык җөмләләр | 2 | Иярчен тәмамлык җөмләнең баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килүе һәм кемне? нәрсәне? нәрсәгә? кемгә? кемнән? нәрсәдән? 21.01кемдә? нәрсәдә? сорауларына җавап бирүе | 24.01<br>25.01 | 16 |
| 58-59 | Иярчен аергыч җөмләләр. | 2 | Иярч23.01ен аергыч җөмләнең баш җөмләнең аергычы урынында килүе һәм 28.01нинди? кайсы? кемнең? сорауларына җавап бирүе. | 30.01<br>31.01 | 18 |
| 60 | Диктант№4 | 1 | Грамоталылык 30.01дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 01.02 | 23 |
| 61-62 | Иярчен вакыт җөмләләр. | 2 | Иярчен вакыт җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын белдерүе һәм кайчан? кайчаннан бирле? кайчанга чаклы? сорауларына җавап бирүе | 6.02<br>7.02 | 26 |
| 63-64 | Иярчен урын җөмләләр. | 2 | Иярчен урын җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең урынын белдерүе һәм кайда? кайдан? кая? кебек сорауларга җавап булуы. | 8.02<br>13.02 | 30 |
| 65 | Беркетмә язарга өйрәнү. | 1 | Эш кәгазьләре үрнәкләре белән танышуны дәвам итү | 14.02 | 1 |
| 66-67 | Иярчен рәвеш җөмләләр. | 2 | Иярчен рәвеш җөмләнең, баш җөмләдәге эш яки хәлнен рәвешен белдерүе һәм ничек? ни рәвешле? кебек сорауларга җавап булуы. | 15.02<br>20.02 | 6 |
| 68-69 | Иярчен күләм җөмләләр. | 2 | Иярчен күләм җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең күләмен белдерүе һәм күпме? никадәр? ни дәрәҗәдә? кебек сорауларга җавап булуы | 21.02<br>22.02 | 8 |
| 70 | Бәйләнешле сөйләм үстерү.<br>Изложение №3 | 1 | Катлаулы план нигезендә эчтәлекне төгәл итеп бирү. | 27.02 | 13 |
| 71-72 | Иярчен сәбәп җөмләләр. | 2 | Иярчен сәбәп җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең сәбәбен белдерүе һәм ник? нилектән? ни сәбәпле? нәрсә аркасында? кебек сорауларга җавап булуы | 28.02<br>5.03 | 15 |
| 73-74 | Иярчен максат җөмләләр. | 2 | Иярчен максат җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең максатын белдерүе һәм ни өчен? нинди максат белән? кебек сорауларга җавап булуы. | 6.03<br>7.03 | 20 |
| 75<br>76-77 | Бәйләнешле сөйләм үстерү.<br>Сочинение-хөкем йөртү.<br>Иярчен шарт җөмләләр. | 1<br>2 | Бәйләнешле сөйләм кунекмәләрен үстерү максатында<br>Иярчен шарт җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнен үтәлү-үтәлмәвенә шарт булган эш яки хәлне белдерүе һәм нишләсә? ни булса? нинди шартларда? кебек сорауларга җавап булуы. белдерүе. | 12.03<br>13.03<br>14.03 | 22<br>27<br>1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 78-79 | Иярчен аныклагыч җөмләләр<br>Иярчен аныклагыч җөмләләр | 1<br>1 | Иярчен аныклагыч җөмләләрнең төзелеше ягыннан аналитк төре булуы. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче аналитик чаралар, тыныш билгеләре<br>Иярчен аныклагыч җөмләләрнең төзелеше ягыннан аналитк төре булуы. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче аналитик чаралар, тыныш билгеләре | 19.03<br>20.03 | 6<br>9 | |
| 80-81 | Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау. | 2 | Бүлек буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту. Кушма җөмләләрне схемаларда күрсәтү күнекмәләре булдыру. **Тыныш билгеләренең куелышы** | 21.03<br>2.04 | 13 | |
| 82-83 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение | 2 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, камилләштерү. Бердәм республика тестлаштыруына әзерлек | 3.04<br>4.04 | 15 | |
| 84 | Диктант№5 | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 9.04 | 20 | |
| 85 | **Катлаулы төзелмәләр** турында төшенчә | 1 | Икедән артык грамматик нигезе булган җөмлә катлаулы төзелмә булуы | 10.04 | 22.03 | |
| 86 | Күп тезмәле катлаулы төзелмә | 1 | Үзара тезү юлы белән бәйләнгән катлаулы төзелмәнең күп тезмәле катлаулы төзелмә булуы **Тыныш билгеләренең куелышы** | 11.04 | | |
| 87 | Күп иярченле кушма җөмлә турында төшенчә. Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә. | 1 | Гади җөмләләрнең үзара ияртү юлы белән генә бәйләнгән катлаулы төзелмәнең күп иярченле кушма җөмлә дип аталуы.**Тыныш билгеләренең куелышы.**Ике җөмләнең бер баш җөмләгә ияреп килеп, һәм ул җөмләләрнең икесе дә мәгънәләре буенча ике төргә караса, андый җөмләләрнең тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә дип аталулары.**Тыныш билгеләренең куелышы** | 16.04 | | |
| 88 | Диктант №6 | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 17.04 | | |
| 89 | Бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә. | 1 | Ике җөмләнең бер баш җөмләгә бер-бер артлы ияреп килүләренең бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә дип аталулары. **Тыныш билгеләренең куелышы** | 23.04 | | |
| 90 | Берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә. | 1 | Күп иярченле кушма җөмләдә җөмләләр үзара тиңдәш иярү, тиңдәш түгел иярү, бер-бер артлы иярү юлы белән (кимендә ике төрле бәйләнеш) бәйләнсәләр, мондый җөмләләрнең берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә дип аталулары. **Тыныш билгеләренең куелышы** | 24.04 | | |
| 91 | Контроль диктант №7 | 1 | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 25.04 | | |
| 92 | Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Иярченле кушма җөмләләр буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту. Кушма җөмләләрне схемаларда күрсәтү күнекмәләрен кабатлау, ныгыту. | 1.05 | | |
| 93-94 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Контроль изложение<br>Бәйләнешле сөйләм үстерү. Контроль изложение | 2 | Катлаулы план нигезендә эчтәлекне төгәл итеп бирү.<br>Катлаулы план нигезендә эчтәлекне төгәл итеп бирү. | 2.05<br>7.05 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 95 | Катнаш кушма җөмлә. | 1 | Гади җөмләләре үзара тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнгән катлаулы төзелмәләрнең катнаш кушма җөмлә дип аталулары. **Тыныш билгеләренең куелышы** | 8.05 | |
| 96 | Катлаулы төзелмәләрне кабатлау, синтаксик анализ ясау | 1 | Гади җөмләләре үзара тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнгән катлаулы төзелмәләрнең катнаш кушма җөмлә дип аталулары. **Тыныш билгеләренең куелышы** | 14.05 | |
| 97 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение | 2 | Бүлек буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту. Кушма җөмләләрне схемаларда күрсәтү күнекмәләре булдыру. | 15.05<br>16.05 | |
| 98 | **Тезем.** | 1 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, камилләштерү. Бердәм республика тестлаштыруына әзерлек | 21.05 | |
| 99-100 | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре | 2 | Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында бик нык җәенкеләндерелгән гади яки кушма җөмләләрнең тезем дип аталулары.**Тыныш билгеләренең куелышы** | 22.05<br>23.05 | |
| 102 | Йомгаклау | 1 | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләренең куелышы | 28.05 | |

**Укыту-методик комплекты**

**Укучырар өчен:** “Татар теле: 8 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015.

**Методик ярдәмлек**

**Укытучы өчен:**

1. «Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар:1-11”- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011.
2. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы (Ф.С.Вәлиев, Г.Р.Саттаров. – Казан. “Раннур”, 2000)
3. Хәзерге татар әдәби теле. (Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. Казан, “Мәгариф”, 2005)
4. Диктантлар җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 5-11 нче сыйныфлары өчен. Укытучылар өчен кулланма/З.Н.Хәбибуллина, Г.Ш.Нәбиуллина. - Казан: Мәгариф, 2006.
5. Татар теленнән изложениеләр җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 сыйныфлары өчен. Укытучылар өчен кулланма/ З.Н.Хәбибуллина, И.Г.Гыйләҗев- Казан: Мәгариф,2003.
6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1977, 1979, 1981.

**Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары**

<u>**Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү:**</u>

Сүзлек диктанты –30-35 сүз

**Сүзлек диктантын бәяләү**

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант- ел башында 130 сүз, ел ахырында 140 сүз

**Контроль диктантны бәяләү:**

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

Изложение текстының күләме

ел башында 350-400 сүз (180-200 –язма күләме)

ел ахырында 400-450 сүз (200-220- язма күләме)

**Изложениене бәяләү**

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5»ле куела. (Берорфографик, икепунктуацион яки ике грамматик хатасыбулырга мөмкин.)

2. Текстнынәчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.

3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.

4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

**Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5»ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)

2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4»ле куела.

3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3»ле куела.

4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2»ле куела.

**Тестны бәяләү**

1.Тестның 90-100% дөрес башкарылган эшкә “5”ле куела.
2. Тестның 75-89% дөрес башкарылган эшкә “4”ле куела.
3.Тестның 65-74% дөрес башкарылган эшкә “3”ле куела.
4.Тестның 0-64% дөрес башкарылган эшкә “2”ле куела.

**Өстәмә материал**

**1.Диктант текстлары.**
**2. Изложение текстлары.**
**3.Тестлар.**

**Өстәмә материал**

**ДИКТАНТ ТЕКСТЛАРЫ**

**Үткәннәрне тикшерү буенча контроль диктант №1**
**(уку елы башында үткәрелә торган язма эш тексты)**
**Китап язмышы – халык язмышы ул.**

(Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлар өчен. Казан, “Мәгариф”, 2006, 150 нче бит)

Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин - татар китабы тарихын өйрәнүче галим.

- Әбрар ага, язма, басма сүз – кешелек дөньясы уйлап чыгарган иң бөек мгҗизаларныд берсе.. бу могҗиза ничек, кайчан барплыкка килгән? – дигән сораудан башлый әңгәмәне язучы Мөдәррис Әгъләмов.
- Беренче китап XI йөздә Кытайда басылып чыга. 1445 нче елдан башлап, бөтен Европага тарала. Татар телендә басылган беренче китап гарәп хәрефләре белән 1612 нче елда Лейпциг шәһәрендә чыга.
- Ә безнең Идел буендагы бабаларыбыз нинди китаплар укыганнар?
- Татарларга басма китап XIV гасырдан бирле таныш, - ди галим. – Италиядә Шәрык илләрендә чыккан китаплар киң таралаган. Ләкин алар гарәп һәм фарсы телләрендә. Халык арасында шуңа күрә кулдан язылган китаплар күп булган. Әле хәзерге көнгә кадәр галимнәр кулъязма китапларны таба торалар. (119 сүз) (М.Әгъләмов)

**Диктант №2**

(Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлар өчен. Казан, “Мәгариф”, 2006, 152 нче бит)

1.Шомлы хәбәрләргә төренгән майның егермесе җитте. Кояшлы җылы яз инде байтак вакыт хакимлек итә, агачлар күптән инде яфрак ярган, үлән сабаклары шаулап буй үстергән, алмагач һәм шомыртларның ап-ак чәчәккә күмелгән бер мәле иде. (Г. Иделле).

2. Таң беленә,

Офык алсулана.

Тып-тын өйләр, кырлар, үләннәр.

Көмеш чыклар кунган миләүшәләр

Күк башларын түбән игәннәр (Р. Вәлиева).

3. Язлар килә,

Кояш көлә,

Бар дөньяга

Нур бөркелә.

Аяз күктән,

Чут-чут итеп,

Жырчыкошлар

Тавышбирә. (Р. Вәлиева).

4. Иртәниртүкторыпйөгерепкайттым да геркүтәрергәтотынган идем, әниәрләргәкереште. ( Н.Акмалов).

*Бирем. Кушмаҗөмләләрнебилгеләргә.*

**Диктант№3**
**( уку елының 1нче яртыеллыгына административ контроль диктант тексты)**
**Яшенле яңгыр**

(Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлар өчен. Казан, “Мәгариф”, 2006, 155 нче бит)

Җәйге бөркү көннәр җиткәч, күктә төркем-төркем йөргән авыр болытлар ешрак күренәләр. Менә алар зәңгәр күкне дә, якты кояшны да каплый. Бер минут тынлык үтүгә, өермә күтәрелә. Аннан, каты шаулап, яңгыр коярга тотына; яшен яшьни, күк күкри, күңелле яңгыр башлана. Җирдән югарыга күтәрелгән су пары, бик нык суынып, тамчыларга әйләнә. Һава агымы аларны астан өскә йөрткәнгә, тамчылар кечкенә боз кисәкләренә әвереләләр. Боз кисәге авырая һәм түбән төшә башлый. Җиргә җитәрәк, алар эри, һәм яңгыр барлыкка килә. Ә кайвакыт җиргә боз да ява.

Ә болыттагы тамчыларның, боз кисәкләренең хәрәкәте тукталмый. Алар, бер-берсенә тиеп, электр белән корылалар. Болытның өске катлавы уңай, ә аскысы кире электр корылмасы алып килгәнлектән, алар арасыннан очкын үтеп китә. Яшен яшьни. Яшен тирә-якны җылытканга, һава бик тиз киңәя һәм шартлый. Күк күкри.

Кара болытлар таралгач салкынайта, сулыш алу җиңеләя. Яшенле яңгыр җирне дә, күкне дә юа.

(«Кем ул? Нәрсә ул?» китабы) (140 сүз)

**3.Тестлар.**

**Диктант №4**

**Кышкы юлда**

(Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлар өчен. Казан, “Мәгариф”, 2006, 156 нчы бит)

Алдагы көндә сине ни көткәнне бервакытта да анык белә алмыйсың. Рушад та урман буендагы юлдан билгесезлеккә атлый.

Әнә кар диңгезе күк белән тоташкан урынннан тәгәрәп кенә кызгылт-сары кояш чыгып килә. Кояш җир йөзенә һәр көн үзенчә чыга, чөнки уз үзенең төсләрен кабатларга яратмый. Бүген ул каты бураннардан соң беренче мәртәбә күренә, шуңадыр кыяфәте арган, йончыган.

Иртәнге салкынча җил, иренеп кенә, басу өстеннән кар сыпырып йөртә. Ул кояш чыгуны тереклек дөньясына хәбәр итә. Кар дәрьясы өстендәге салкынча тыгыз һава аркылы узган кояш нурлары зәгыйфь саргылт төскә кергәннәр. Кояш тирәсендә ниндидер бозра. Ул бозра офыктагы аксыл томанга асып куелган кебек. Җил кар өстендә имән яфракларын шудыртып йөртә. Имән яфраклары быел да коелып бетмәгән икән. Агач яфрагы коелып бетмәсә, елны авыр килә диләр. Сугыш беткәч, тагы нинди авырлык килер икән халыкка? Хәер, ел авыр, бик авыр. Тик хәзер үлем, кан коюю гына юк. Шул уйлар белән Рушад кар диңгезе өстеннән атлый. Башында бер уй һич тынгылык бирми: алданиләр көтә аны?

(158 сүз) (М.Мәһдиев)

**Диктант №5 (контроль)** (“Иярчен кушма җөмләләр” темасы буенча)

(Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлар өчен. Казан, “Мәгариф”, 2006, 168 нче бит)

1. Сабир кайтып җитә алмады: чана юлы төшмәгән иде әле. (М. Әмир). 2. Кәефе кырылу сәбәпле, соңгы кадакларга ул катырак, хәтта ачу белән сукты. 3. Төнлә сибәләп узган яңгыр комлы юлны чылатып өлгермәгән,шуңа күрә бу аз йөрелгән юл, вакыт- вакыт ком чүленә әйләнеп, безнең юлчыларны әледән- әле тоткарлый иде. 4. Өең буш булса да, күңелең буш булмасын.5. Билгеле: ул заманда авылда китап дигән нәрсә алай күп түгел иде әле. 6. Бу тәвәккәллек аңа шулкадәр зур рәхәтлек бирде ки, аның шатлыктан тонган күзләре бернәрсә күрмиләр иде. 7.Кар өстенә учлап энҗе сипкәннәрмени, дөнья мең төрле төсләргә кереп җемелди. 8. Сугыш узган якларда булгаладым. 9. Ботаклар битне сыдырмасын өчен, алар бик сак булдылар. 10.Язмышлар аерылуда үз гаебе дә барлыгы ачыклангач, егетнең йөрәге бигрәк тә сыкрап типте.

*Бирем. Иярчен җөмләләрнең төрләрен билгеләргә, схемада күрсәтергә.*

**Диктант №6** (“Күп иярченле кушма җөмләләр” темасы буенча)

**Колын**

(Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлар өчен. Казан, “Мәгариф”, 2006, 171 нче бит)

Җәй башында безнең җирән кашка колын алып кайтты.

Хәзер мин, бүтән уеннарымны онытып, көнозын колын тирәсендә бөтерелә башладым. Иртән торуга, иң беренче куанычымшул: ипи йомшагы эләктерәм дә колын янына чыгам. Баштаракул, мин янынакерүгә, тизрәканасынабарыпсыенаторганиде. Тора-бара ияләнде. Мин дәшкәч, колакларынторгызып, борылыпкарыйторганбулды. Бераздан, матурборынтишекләренселкеткәләп, ипиисни башлады. Аннарыкөлтөслезәңгәрсу-соры, хәтфәкисәгешикеллейомшакиреннәребеләнучтөбеннәнипиисыныкларыэләктерепалыргаөйрәнде.

Өммикамалапазәңгәрсатиннанмуенсатегепбиргәч, колынныңмуенынакечкенәгенәшөлдертагыпҗибәрдек. Колынбашынселкеткәнсаен, улгаҗәпсөйкемлетавышларчыгара, әйтерсең, чың-чыңитеп, берьюлыәллә ни тиклекөмештәңкәкоела. (110 сүз) (Г. Бәширов).

*Бирем. Күпиярченлекушмаҗөмләнеаерыпязарга, схемасынтөзергә, төренкүрсәтергә.*

**Диктант №7**

**(2017-2018 нче уку елы арадаш аттестация эшенә контроль диктант тексты)**

**Көнбагыш дус**

(Диктантлар җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлар өчен. Казан, “Мәгариф”, 2006, 172 нче бит)

Кәрим сизенә килде: кояш белән көнбагыш арасында нинди дер уртаклык, яшерен бәйләнеш бар, чөнки бакчадагы дусты кояш әйләнеше уңаена көнозын талгын гына борыла икән бит. Кояш иртән кай яктан чыкса, көнбагыш шул якка караган була. Кичләрен чуклы –чуклы башын кояш баешы ягына бора. Көнбагышның җанлы икәнлегенә ышанды Кәрим, шуңа күрә ул аны иң якын дусты итеп таныды. Сентябрь җиткәч, беренче сыйныфка укырга барачагы хакында озаклап сөйләде. Дусты аны бирелеп тыңлады. Көнбагышның дәү-дәү яфраклары кулларына орынганда, Кәрим сәер пышылдау ишетә: син тиздән мәктәпкә барасың, зур үсәсең.

Өлкәннәргә серләреңне сөйләсәң дә, алар сине күп вакыт аңлап бетермиләр. Кәрим шуңа төшенде: сөйләшер, серләшер өчен, көнбагыштан да яхшы һәм ышанычлы иптәш юк, чөнки ул алдашмый, үртәшми